ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)3-92-40, факс (84366)3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**әл КАРАР**

**« 22 » май 2026 ел** **№ 13**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында” 2021 елның 28 апрелендәге 11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында (2023 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы үзгәрешләр белән)**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” 2025 елның 31 маендагы 828 номерлы карары нигезендә һәм норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Апаз авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында” 2021 елның 28 апрелендәге 11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә (2023 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының максатка ярашлылыгы критерийлары булып торалар:

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының муниципаль программаларның максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе;

ташламалар алу хокукыннан файдаланган түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының яисә түләүчеләрнең гомуми санының 5 еллык чорга нисбәтендә характерлана торган бирелгән ташламаларны түләүчеләрнең ихтыяҗы.

Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары әлеге пунктта күрсәтелгән критерийларның берсенә генә булса да туры килмәгән һәм (яки) муниципаль программа максатларына һәм (яки) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәт максатларына ирешү күрсәткеченең (индикаторның) әһәмиятен үзгәртүгә түләүчеләр өчен каралган ташламалар кертемен бәяләүнең уңай күрсәткечләренә ирешмәгән очракта, муниципаль программа максатларына һәм (яки) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын куллану нәтиҗәлелегенең югарырак күрсәткечләренә ирешкән очракта, муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәләре буенча салым чыгымнары кураторына җирле администрациягә түләүчеләр өчен ташламаларны саклау турында (төгәлләштерү, гамәлдән чыгару) тәкъдимнәр кертергә кирәк.».

1.2. 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль программа максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешү күрсәткеченең (индикаторының) әһәмиятен үзгәртүгә түләүчеләр өчен каралган ташламаларның өлешен бәяләүне, муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүне үз эченә ала.».

1.3. 16 пунктның “в” пунктчасында “норматив” сүзен “хокукый” сүзенә алмаштырырга.

1.4. Түбәндәге эчтәлекле 16.1 пункт өстәргә:

«16.1. Муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләүне түбәндәгегә карата уздырмау каралган:

а) муниципаль берәмлекләрнең техник салым чыгымнары;

б) муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләүне уздыру вакытына фискаль характеристикалары булмаган муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнары;

в) муниципаль берәмлекләрнең гамәлдә булу срогы бер елдан кимрәк булган ташламаларга бәйле салым чыгымнары.».

1.5. Түбәндәге эчтәлекле 16.2 пункт өстәргә:

«16.2. Бирелгән ташламаларны түләүчеләр тарафыннан таләп ителүне бәяләүне түбәндәгеләргә карата уздырмау каралган:

а) муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләүне уздыру вакытына фискаль характеристикалар булмаган муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарына бәйле ташламалар;

б) муниципаль берәмлекләрнең гамәлдә булу срогы бер елдан кимрәк булган ташламаларга бәйле салым чыгымнары.».

2. Әлеге карарны “Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында” (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Апаз авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе — Р.Ф.Котдусов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "АПАЗОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" ОГРН 1061683005689
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АПАЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609009805